**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 21 «22» декабрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 42 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 №425-ФЗ Федераль закон нигезендә

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 42 номерлы карарына (02.11.2015 №10, 04.05.2018 №21, 13.11.2018 №59, 13.12.2018 №66, 21.06.2019 №25, 25.11.2019 №48, 19.03.2021 №11, 28.11.2024 № 48 карарлар редакциясендә) үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 пунктчасындагы икенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«- Һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2025-2027 елларның күчеш чорына 2 процент, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган тәгалләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш.»;

1.2. 2 пунктның 4.1 пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aznakayevo.tatastan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә һәм үз көчен 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис А.Л. Севостьянов